Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Околоток-Яңасала авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

07 ноябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 07 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Околоток-Яңасала авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Чаллы-Баш авылында юл төзекләндерү (авылга керү, чыгу);
- Яңавыл авылында Киров урамы юлларын төзекләндерү;
- Чаллы-Баш авылындагы сууткәргеч электр сибын алыштыру;
- Околоток-Яңасала авылында сууткәргеч торбаларны алыштыру.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 368 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 199 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 199 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге составына керүче Околоток-Яңасала авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Околоток-Яңасала авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп

укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Чаллы-Баш авылында юл төзекләндерү (авылга керү, чыгу);
- Яңавыл авылында Киров урамы юлларын төзекләндерү;
- Чаллы-Баш авылындагы суүткәргеч электр сибын алыштыру;
- Околоток-Яңасала авылында суүткәргеч торбаларны алыштыру.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Фәтхетдинов урамы, 10 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Камалиев И.И.

Биектау авыл җирлеге башлыгы: Камалиев И.И.

СОВЕТ БИЕКТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ